## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Чәкән торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**05 декабрь 2021 ел** **№2**

2003 елнын 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Чәкән торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Чэкэн торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иту буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Чәкән торак пунктының Яңа урам буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау);
- Чәкән торак пунктында урамнарны яктыртуны карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, лампаларны, яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Чәкән авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү).
- Чәкән торак пунктында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Чәкән авылы торак пунктында балалар спорт комплексын сатып алу, җыю, урнаштыру.

2. 2020 елда Чәкән авылындагы Ык елгасы аша күперне ремонтлауга каралган һәм файдаланылмаган 5 мең сум күләмендәге үзара салым акчаларын 2022 елда Чәкән торак пунктының Яңа урам буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга (асфальт-бетон өслекле юлларның чокырларын ямау) юнәлтергә.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми

сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: И.Б. Бохарова